**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында**

2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын, 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү өчен билгеләнгән спорт объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) капиталь төзекләндерү, шулай ук 2018 елгы FIFA футбол буенча дөнья чемпионатын, 2017 елгы FIFA Конфедерацияләр кубогын әзерләү һәм үткәрү өчен билгеләнгән спорт объектларына кермәгән инфраструктура объектларын төзү процессында төзелеш контролен гамәлгә ашыру максатларында **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасын раслау турында» 2011 елның 24 сентябрендәге ПУ-585 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2012 елның 20 гыйнварындагы ПУ-33 номерлы, 2013 елның 11 сентябрендәге ПУ-892 номерлы, 2014 елның 6 мартындагы ПУ-258 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2015 елның 8 июнендәге ПУ-543 номерлы һәм 2016 елның 12 августындагы ПУ-683 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-80 номерлы, 2014 елның 10 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2014 елның 5 мартындагы ПУ-244 номерлы, 2014 елның 20 мартындагы ПУ-286 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2014 елның 26 апрелендәге ПУ-435 номерлы, 2014 елның 2 июлендәге ПУ-636 номерлы, 2014 елның 12 сентябрендәге ПУ-854 номерлы, 2014 елның 28 ноябрендәге ПУ-1091 номерлы, 2014 елның 5 декабрендәге ПУ-1107 номерлы, 2015 елның 16 мартындагы ПУ-289 номерлы, 2015 елның 18 мартындагы ПУ-294 номерлы, 2015 елның 25 мартындагы ПУ-367 номерлы, 2015 елның

17 июнендәге ПУ-562 номерлы, 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы, 2015 елның 29 июлендәге ПУ-680 номерлы, 2015 елның 10 сентябрендәге ПУ-850 номерлы, 2015 елның 24 сентябрендәге ПУ-892 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 6 апрелендәге ПУ-331 номерлы, 2016 елның 19 апрелендәге ПУ-366 номерлы һәм 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 20 пункттагы «155» санын «156» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 06 декабрь
№ ПУ-1075

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның «06» декабрендәге
ПУ-1075 номерлы Указына
кушымта

# Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасы

